КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 апрель г.Казань № 341

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 182 нче карары белән расланган Бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 13 март, 182 нче карары белән расланган Бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә эшчәнлеге туктатылмаган;»;

6 пунктта:

җиденче абзацка «һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^{1}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар күрсәтелгән чор өчен» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында күчемсез милек объектлары, җир кишәрлекләре һәм аренда ставкалары бәяләре мониторингы формасында соңгы биш елда башкарылган аналитик тикшеренүләрнең төп нөсхәсе яки электрон документ рәвешендә бирелә торган макетлары;»;

унбишенче абзацта «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, эшчәнлек Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисап бирү вакыты һәм формасы;»;

түбәндәге эчтәлекле $13^{1}$ пункт өстәргә:

«$13^{1}$. Кирәк булганда, Министрлык субсидия алучы белән килешүне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

17 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Субсидия алучылар министрлыкка субсидия бирү елының 31 декабренә кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыралар.»;

икенче абзацта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзенә алмаштырырга;

19 пунктта:

дүртенче абзацта «субсидияне билгеләнгән срокта файдалану турында» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзенә алмаштырырга;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымта өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин